**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2022 № 120

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2нче кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының “Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында" 2021 ел, 1 февраль, 39 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка игълан итәргә һәм әлеге карарны Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның 28
гыйнварындагы 120 номерлы
карарына 1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2 537,00 |
| 3. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 023,81 |
| 4. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 3 403,87 |
| **Барлыгы** | **6 964,68** |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы 120 номерлы карарына 2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү (төрү) | 1 206,28 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1 330,80 |
| 4. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1023,77 |
| 5. Җирләү  хезмәте (кабер казу һәм  җирләү ) | 3 403,83 |
| **Барлыгы** | **6 964,68** |